КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 28 декабрь г.Казань № 1067

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясын тормышка ашыру максатында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 909 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен раслау турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы, «Дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) һәм муниципаль тикшерүдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм индивидуаль эшмәкәрләр хокукларын яклау хакында» 2008 елның 26 декабрендәге, 294-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре

турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 һәм 2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) һәм социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм социаль хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итүчеләр күрсәткән хезмәт күрсәтүләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуын тәэмин итүдә төбәк дәүләт тикшерүен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруны оештыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы дип Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын билгеләргә.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт тикшерүендә (күзәтчелегендә) тотуны гамәлгә ашыруны оештыру тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

2. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин